


9 августта, Физкультурачылар коне алдыннан, Республика Йортында әйдәп баручы спортчыларны һәм тренерларны хормәтләv булды. Спортчыларга һәм аларнын остазларына лаеклы бvләкләрне Мордовия Правительствосы Рәисе Владимир Фёдорович Сушков тапшырды. Бу традиция инде берничә ел vзгәрешсез кала. Чарада Мордовия вице-премьеры Галина Алексеевна Лотванова, Мордовия спорт, яшьләр сәясәте һәм туризм министры Александр Владимирович Савилов катнашты.
Үзенен сәламләv сvзендә премьер узган ел спорт ареналарында ирешкән ин әһәмиятле жинvләр турында искә тошерде. Бу, аерым алганда, Яшvсмерләр Олимпия уеннарында **В арвара Овчинникова**
- «алтын»,
**Артем Сурков һәм Сергей Емелин**
корәшчеләренен донья чемпионатында икелэтә триумфлары. Узган ел барлыгы уноченче регион спортчылары халыкара һәм ботенроссия ярышларында 1100 дән артык медаль яуладылар. Жинv тантанасын безнен спортчылар быел да дәвам итә. Үткән алты ай эчендә генә дә алар Мордовия жыелмасы копилкасына 700гә якын бvләк китерде инде.
**Владимир Фёдорович Сушков**
Европа чемпионатында һәм Европа уеннарында корәшчеләрнен унышын һәм велоузышчыларнын континенталь Беренчелегендә лаеклы чыгыш ясавын да билгеләп vтте. Хәзерге вакытта спорт торләре буенча Россия жыелма командалары составына Мордовиядән 153 кеше керә, дип ишеттерде.
Республикада сәламәт яшәv рәвешен пропагандалауга зур игътибар бирелә. Мордовия Хокvмәте Рәисе сvзләренә караганда, хәзерге вакытта Мордовиядә халыкнын 43 проценты даими рәвеш-тә физкультура һәм спорт белән шогыльләнә. 2024 елга аларнын саны 53 процентка кадәр артырга тиеш, диде.
Владимир Фёдорович Сушков котлавыннан сон сигез кешегә дәvләт бvләкләре һәм «Лауреат премии Главы Республики Мордовия» исеме **Бояровлар** (3 кеше) спорт династиясенә тапшырды. Ә барлыгы Ботенроссия һәм Халыкара ярышларында ирешкән югары спорт нәтижәләре очен Мордовия Республикасы Главасы Дипломнары һәм премияләре белән 140 спортчыны һәм 17 яшькә кадәрге балалар белән эшләv буенча ин

яхшы 33 тренер – укытучыны бvләкләде.
Бvләкләнvчеләр арасында, һәрвакыттагыча, татарлар да аз тvгел иде. Шулай, жинел атлетика кебек спорт торләре буенча югары нәтижәләргә ирешкән спортчылар: **Дарья Шамиль кызы Голубечкова**
(яшvсмер кызлар арасында спорт йореше буенча Россия Кубогы жинvчесе),
**Эльвира Марат кызы Салькаева**
(яшvсмер кызлар арасында спорт йореше буенча Россия кубогынын комеш призеры),
**Лиана Руслан кызы Эшниязова**
(спорт йореше буенча Россия кубогынын бронза призеры) - алар рәсемдә,
**Эльвира Альберт кызы Хасанова**
(яшvсмер кызлар арасында йорv буенча Россия беренчелеге жинvчесе) бvләкләнделәр.


Спорт корәше, дзюдо буенча югары спорт нәтижәләренә ирешкән спортчылар: **Руслан Рустам улы Бичурин**
(ир-атлар арасында спорт корәше буенча Россия чемпионаты жинvчесе),
**Денис Мянсур улы Муртазин**
- рәсемдә (ир-атлар арасында спорт корәше буенча Россия чемпионаты жинvчесе),
**Дамир Рамиль улы Рахимов**
(яшvсмерләр арасында грек-рим ко-рәше буенча Россия беренчелегенен бронза призеры) тантаналы рәвештә бvләкләр алдылар.
Олимпия булмаган спорт торләрендә югары спорт нәтижәләренә ирешкән **Рифат Раис улы Резяпов,**
яшvс-мерләр арасында каратэ буенча донья бе-ренчелегенен бронза призеры, тантаналы бvләкләнvчеләр арасында иде.
Мордовия Главасы Гранты белән 17 яшькә кадәрге балалар белән эшләv буенча тренер – укытучылар (тренерлар) - **Римма Харис кызы Девяткина,** «Е. В. Швецов исемендәге сурдлимпия һәм паралимпия резервы спорт-адаптив мәктәбе» тренеры һәм
**Надиря Мизамбидин кызы Катюкова,**
«Кышкы спорт торләре буенча олимпия резервы спорт мәктәбе» тренеры котландылар.
Бvләкләv тантанасы ахырында Владимир Фёдорович Сушков спортчыларга һәм тренерларга яна жинvләр теләде, аларны спорт коче һәм Мордовиянен боеклеге дип атады.

**Наилә Насырова**